| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БИШНИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БИШНӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**2024 елның 21 ноябре** Бишня ав. **№ 56**

Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлеге Башкарма комитетының Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлеге Башкарма комитетының 2023 елның 01 сентябрендәге 33 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Бишнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты керемнәренең баш администраторларының бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибенә үзгәрешләр кертү турында.

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 160.1 статьясы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлеге башкарма комитеты **КАРАР ИТӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлеге Башкарма комитетының Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлеге Башкарма комитетының 2023 елның 01 сентябрендәге 33 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Бишнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты керемнәре баш администраторларының бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5 пунктның «б» пунктчасының алтынчы абзацында «тапшыру» сүзеннән соң «түләнергә тиешле сумманы исәпләү гамәлгә ашырылган көннән дә соңга калмыйча»сүзләрен өстәргә.

1.2. 5 пунктның «б» пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү;

бюджетка түләүләр, алар буенча пенялар һәм штрафлар буенча дебитор бурычларын түләтү вәкаләтләрен гамәлгә ашыруның Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләр нигезендә эшләнгән регламентын билгеләү;

Россия Федерациясе Бюджет кодексында һәм аның нигезендә кабул ителә торган бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган муниципаль хокукый актларда билгеләнгән башка бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыру.».

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru («Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында: Бишнә авылы, Үзәк урамы, 5 (Советның административ бинасы), Бишнә авылы, Школьная урамы, 10 (Бишнә авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Бишнә авыл**
**җирлеге башлыгы:** **И.М.Фатхуллин**